ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРО-МАВРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ МАВРИН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул. Центральная, д. 2а, с. Старое Маврино,
Заинский район, 423537

Үзәк урамы, 2а йорт, Иске Маврин
авылы, Зәй районы, 423537

Телефон, факс 885558 6-20-01. Электронный адрес: Smavr.Zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**02.02.2026** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы «2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» карары, Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Уставына таянып, Иске Маврин авыл җирлегең башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2026 елның 01 февраленнән Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 9165,37 сум күләмендә, 1-нче һәм 2-нче кушымталар нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында” 2025 елның 31 гыйнварындагы 2 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
5. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Г. Нургалеев**

Зәй муниципаль районы
Иске Маврин авыл җирлеге
башкарма комитетының
02.02.2026 ел
2 номерлы карарына
1 нче кушымта

2026 елның 01 февраленнән
Иске Маврин авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 681,24 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1 573,46 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 423,93 |
| Барысы | 9 678,63 |

Зәй муниципаль районы
Иске Маврин авыл җирлеге
башкарма комитетының
02.02.2026ел
2 номерлы карарына
2 нче кушымта

2026 елның 01 февраленнән
Иске Маврин авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 1 009,41 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 747,27 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1 535,83 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 386,12 |
| Барысы | 9 678,63 |